ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2019 п.г.т.Алексеевское № 45

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районында
җирләү хезмәтләренең гарантияле
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 12 гыйнвар,1996 ел, 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында»“Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакындагы” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 18 май, 2007 ел, 196 нчы карары,«2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гыРоссия Федерациясе Хөкүмәтенең 24 гыйнвар, 2019 ел, 32 нче карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында”гы 2018 ел, 31 гыйнвар карарын 2019 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан РеспубликасыАлексеевск муниципаль районы рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернетчелтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне инфраструктур үсеш мәсьәләләре буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
__31.01.2019_№ __45___

**2019 елның 1 февраленнән**
**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында**
**җирләү хезмәтләренең гарантияле**
**исемлеге бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләр бәясе** ***(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләр бирү һәм китерү | 2616,47 |
| 3. Мәетне зиратка илтү | 730,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

**Башкарма комитет эшләре белән**
**идарә итүче** **Г.Ә.Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
__31.01.2019___№ __45___

**2019 елның 1 февраленнән**
**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында**
**җирләү хезмәтләренең гарантияле исемлеге**
**бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләр бәясе*(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү | 260,00 |
| 3.Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләр бирү | 2376,47 |
| 4. Мәетне зиратка илтү | 740,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2570,00 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

**Башкарма комитет эшләре белән**
**идарә итүче** **Г. Ә. Йосыпова**